30.11.2024 1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Урман Морквашы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны тотуның конкрет юнәлешләренә юнәлдерүгә ризамы? - Урман Морквашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2024 елның 30 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 60 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 31 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 31 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны тотуның конкрет юнәлешләренә юнәлдерүгә ризамы?- Урман Морквашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча карарны кабул итәргә.

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында халык җыены нәтиҗәләрен Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов